РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ БОЛЬШЕЧЕКМАКСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МУСЛЮМОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ОЛЫ ЧАКМАК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

*423993, РТ, Муслюмовский район. с. Большой Чекмак, ул. Центральная 1,*
Bchak.Mus@tatar.ru *тел. (8-85556) 3-10-97*

с. Большой Чекмак «07» апрель 2021 ел

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ № 7** **КАРАР № 7**

**«Олы Чакмак авыл җирлеге территориясендә стационар булмаган сәүдә объектын урнаштыру һәм эксплуатацияләү хокукына рөхсәт бирү» Олы Чакмак авыл җирлеге Башкарма комитетының 27.02.2017ел, 5 номерлы карары белән расланган муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында**

Төп муниципаль актка үзгәрешләр кертә торган муниципаль акттагы хаталарны төзәтү зарурлыгына бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Олы Чакмак авыл җирлеге Башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. Олы Чакмак авыл җирлеге Башкарма комитетының 27.02.2017ел, 5 номерлы карары белән расланган «Олы Чакмак авыл җирлеге территориясендә стационар булмаган сәүдә объектын урнаштыру һәм эксплуатацияләү хокукына рөхсәт бирү» муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2.6.2 пунктының соңгы абзацын төшереп калдырырга;

1.2. 2.8 пунктының соңгы абзацын төшереп калдырырга;

1.3. 2.9 пунктны түбәндәге эчтәлекле абзац белән тулыландырырга:

«Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурыч булу.»;

1.4 3.3 пунктының 2) пунктчасын түбәндәге редакциядә бирергә:

«2) ведомствоара гарызнамәләр җибәрә:

салым органында исәпкә кую, салым, җыемнар, пенялар һәм законнарны бозган өчен штрафлар түләү буенча бурычлар барлыгы (юклыгы) турында Татарстан Республикасы буенча Федераль салым хезмәте идарәсенә.».

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга һәм Мөслим муниципаль районы Олы Чакмак авыл җирлегенең рәсми сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга (http://pravo.tatarstan.ru).

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

**Олы Чакмак авыл җирлеге**
**Башкарма комитеты җитәкчесе** **Габидуллин И.М.**